| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 11 ноябре № 13/2

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карары проекты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 һәм 92 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты проектын беренче укылышта кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турында» Чүпрәле муниципаль районы Советы карары проектын «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга.
3. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турында» Чүпрәле муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2021 елның 6 декабренә 10:00 сәгатьтә район Мәдәният йортында (тамаша залы) билгеләргә.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары нигезендә үткәрелә, ул Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның Рәсми порталында бастырылган.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турында» Чүпрәле

муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм карарга.

5. Чүпрәле муниципаль районы Советы аппаратына һәм Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль район Советы Рәисе урынбасары А.Е. Ярухинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советынаң 2021 елның 11 ноябрендәге 13/2 номерлы карарына кушымта

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты турында» карар проекты хакында

**«1 статья**

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 761992,42 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 761992,42 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгы юк.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2023 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 766206,12 мең сум һәм 2024 елга 770665,12 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2023 елга 766206,12 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 13765,56 мең сум, һәм 2024 елга 770665,12 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 27724,61 мең сум күләмендә;

3) 2022 елга һәм 2024 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгы юк.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләргә.

**2 статья**

1. Чүпрәле муниципаль районының 2023 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиген нуленче мәгънәсе белән Россия Федерациясе валютасында Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча расларга.

2. 2024 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән

Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле күрсәткеч белән расларга.

3. 2025 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле күрсәткеч белән расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган керемнәрнең күләмен әлеге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2022-2024 елларда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына 2021 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешен кертү 2022 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

**5 статья**

1. Бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бүлүне әлеге Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. Чүпрәле муниципаль районының максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. 2022 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 10457,2 мең сум, 2023 елга 10710,8 мең сум һәм 2024 елга 10974,5 мең сум күләмендә расларга.

**6 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге Карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга:

2022 елга - 42260,6 мең сум.

2023 елга - 42278,3 мең сум.

2024 елга - 42480,4 мең сум.

**7 статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга:

2022 елга - 2127,8 мең сум.

2023 елга - 2200,3 мең сум.

2024 елга - 2279,0 мең сум.

**8 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 576239,92 мең сум, 2023 елда 568012,42 мең сум, 2024 елда 559888,52 мең сум күләмендә әлеге Карарның 8 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**9 статья**

2022 елга Чүпрәле муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 16500 мең сум, 2023 елга 17200 мең сум, 2024 елга 17300 мең сум итеп расларга һәм аларны Чүпрәле муниципаль районының гомуми кулланылыштагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга 2022-2024 елларга җибәрергә.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хакимияте органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хакимияте органнарына, Чүпрәле муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирү белән бәйле карарлар кабул итүдән тыш.

2. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәткәрләрнең һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның санын арттыруга китерә торган карарларны 2022 елда кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**11 статья**

2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты акчаларының калган өлешен, 2021 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы исеменнән төзелгән контрактлар суммасыннан артмаган күләмдә, 2022 елда әлеге максатларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә дип билгеләргә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Чүпрәле районы буенча территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Чүпрәле муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**13 статья**

Әлеге Карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**14 статья**

Әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырырга.».

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгы урынбасары: А.Е. Ярухин